Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы
“7нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе”
муниципаль бюджет гомуми  белем учреждениесе

# “Илең турында уйла...”
# темасына дәрес эшкәртмәсе

**Төзеде:** беренче квалификацион
категорияле татар теле һәм
әдәбияты  укытучысы
Андреева Миләүшә Рәшит кызы

Мәгариф, Казан,  2016 нчы ел

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Сыйныф** | 5 (татар төркеме) | | |
| **Дәрес темасы** | Илең турында уйла... | | |
| **Максат һәм бурычлар** | 1. Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү, “Ватаным өчен” шигырен укып анализлау<br>2. Сөйләм телен үстерү, фикерләү сәләтен үстерү өчен шартлар тудыру<br>3. Сугышчыларның батырлыгын ассызыклау. Туган ил азатлыгы өчен башларын салган батырларга тирән хөрмәт, алар белән горурлану , патриотлык хисләре тәрбияләүне дәвам итү | | |
| **Дәрес тибы** | Яңа материалны аңлату | | |
| **Дәреслек** | Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина “Татар әдәбияты”, 5нче сыйныф | | |
| **Җиһазлау** | компьютер, проектор, экран, слайдлар, аудиоязма, сораулар язылган карточкалар; Фатих Кәрим әсәрләреннән күргәзмә | | |
| **Шәхси УУГ** | Шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү | | |
| **Танып-белү УУГ** | Аңлап әйтеп бирү | | |
| **Коммуникатив УУГ** | Үз фикерләрен җиткерә белү | | |
| **Регулятив УУГ** | Үз фикерләрен раслау өчен дәлилләр сайлый белү | | |
| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | | **Укучы эшчәнлеге** |
| 1. Оештыру<br>Максат: мотивлаштыру | Исәнләшү<br>Мотивлаштыру | - Хәерле иртә, укучылар!<br>- Дәресебезне без өйрәнәчәк авторның сүзләре белән башлап китәсем килә.<br>**Үлем турында уйлама,**<br>**Илең турында уйла,**<br>**Илең турында уйласаң -**<br>**Гомерең озын була.** | Исәнләшү.<br>Тыңлау |
| 2. Өй эшен тикшерү этабы төшеп кала | Проект эше дәрес башланганчы җыелып алына | | М.Җәлил турындагы проект эшен тапшыралар |
| 3. Актуальләштерү<br>Максат: Белгәннәрдән чыгып, белмәгәннәрне ачыклау | “Ватан, батырлык” төшенчәләрен ничек аңлауларын тикшерү.<br><br>“Фо бокс | - УК, “ватан, батырлык” төшенчәләрен сез ничек аңлыйсыз ?<br>- УК, каләмнәрегезне алып алдыгыздагы кәгазь битенә үз фикерләрегезне языгыз әле.<br>-1,3нче өстәлләр “Нәрсә | “Ватан, батырлык” төшенчәләрен “Фо бокс синектикс” структурасын кулланып аңлаталар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | синектикс" структурасын куллану | ул Ватан", 2,4нче өстәлләр "Нәрсә ул Батырлык" соравына җавап яза.<br>Башладык.<br>Эшне тәмамладык, тикшерәбез. 1нче өстәлдән ... җавап бирә, ... | |
| 4. Уку мәсьәләсен кую<br>Максат: чишәсе проблеманы ачыклау | Ф. Кәрим турында кыскача мәгълүмат бирү (презентация) | - УК, хәзер без әсәрләрендә батырлык, ватанны ярату чагылыш тапкан шагыйрь Ф.Кәрим турында мәгълүмат белән танышырбыз. Сугыш шартларында ул үзенең чын кеше, чын патриот булуын ничек раслый икән?<br>Карыйбыз экранга. | Презентация карыйлар, сорауга (Ф.Кәрим сугыш шартларында үзенең чын кеше, чын патриот булуын ничек раслый?) җавап бирәләр |
| 5. Уку мәсьәләсен чишү<br>Максат: Проблеманы чишү өстендә эш | "Ватаным өчен" шигырен аудио язмада тыңлау,<br><br><br><br><br><br><br><br>Шигырьне уку | - УК, Ф.Кәримнең сугыш чорына караган "Ватаным өчен" шигырен тыңлаганчы экрандагы сорауларга (6-слайд) карыйк әле.<br>- Әлеге сорауларны эчтән укып чыгыгыз, шигырьдән аларга җавап эзләрбез<br>- Ә шигырьне без аудиоязмада тыңларбыз.<br>- УК, хәзер китапларыбызның ... битен ачабыз, шигырь эчтән укып чыгыгыз<br>- Шигырьне кычкырып, Шигырьне сәнгатле итеп безгә ___укыр (яисә чылбыр буенча) | <br>"Ватаным өчен" шигырен тыңлыйлар, укыйлар. |
| | Шигырьне анализлау | - Әсәр ни өчен "Ватаным өчен" дип аталган?<br>- Шигырьгә башка исем табып буламы?<br>- Сез шагыйрь булсагыз, нинди исем куяр идегез?<br>- Шагыйрь кемгә хат яза?<br>- Ул үлем килгәнне көтеп ятамы?<br>- Ф.Кәрим ни өчен борчыла?<br>- Герой алдында нинди бурыч тора? | "Ватаным өчен" шигырен укып анализлыйлар. Авторның ни өчен борчылуын, лирик геройның нилектән үлем турында уйлавын шигырь юллары белән дәлиллиләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | - Ул бурычны ул үтиме?<br>- Нилектән үлем турында уйлана?<br>- Шагыйрь тормышны яратамы?<br>Җавапларыгызны шигырь юллары белән дәлилләгез | |
| | Бөек Җиңүнең 70 еллык юбилее турында сөйләшү | - УК, бүген без дәрестә Ф Кәримнең иҗатында сугышчыларның батырлыгын карап үттек . Алар сугыш вакытында үзләрен чын патриотлар итеп күрсәткәннәр. Әлеге кыю сугышчылар арасында, бәлки, сезнең дә бабаларыгыз булгандыр. Сезгә шундый өй эше: Сугышта катнашкан бабаларыгыз турында мәгълүмат әзерләргә.<br>- УК, май аенда нинди бәйрәм булачак?<br>-Бөек Җиңүнең ничә еллык юбилее билгеләп үтелде? | Сугышта катнашкан бабалары турында мәгълүмат әзерләргә иҗади эш алалар |
| | МОДЕЛЬ ФРЕЙЕР структурасы. БАТЫРЛЫК дип язылган модель фрейер таратыла | - УК, хәзер мин сезгә тараткан кәгазь битләренә БАТЫРЛЫК дип язылган. Беренче баганага батырлык өчен кирәкле компонентлар, икенче баганага мисаллар, өченче баганага батырлык өчен мөһим булмаган компонентлар мисаллар, дүртенче баганага тискәре мисаллар язабыз. Һәр кәгазь битен төркем киңәшләшеп тутыра. Эшне башладык | МОДЕЛЬ ФРЕЙЕРны тутыралар |
| 6. Рефлексия<br>Максат: сорауларга җавап биреп, үз эшчәнлекләренә бәя бирү | Дәрескә йомгак. Җөмләләрне язып бетерергә | - УК, хәзер мин сезгә тараткан кәгазь битләренә бүгенге дәрес турында фикерләрегезне язуыгызны үтенәм.<br>*Мин бүген дәрестә _________ өйрәндем.*<br>*Кызыклы булды: ______* | үз хезмәтен бәяли белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | *Кыен булды: _____*<br>*Мин ____ аңладым.*<br>*Мин үземнең ___ тойдым.*<br>*Мине ____ гаҗәпләндерде.*<br>*Мин _____ телим.*<br>*Мин ___ билгесенә лаек* | |
| 7. Өйгә эш<br>Максат: үз мөмкинлекләреннән чыгып биремнәрне сайлап алу | 3 төрле бирем бирү | 1. Шигырьне сәнгатьле укырга, Ф.Кәримнең биографиясен өйрәнергә<br>2. Ф.Кәрим турында өстәмә мәгълүмат яисә презентация әзерләргә<br>3. Сугышта катнашкан бабаларыгыз турында мәгълүмат әзерләргә | үз мөмкинлекләреннән чыгып биремнәрне сайлап алалар |

АЙЛЫК ИҖТИМАГЫЙ-ПЕДАГОГИК
ҺӘМ ФӘННИ-МЕТОДИК
ГОМУМТАТАР ЖУРНАЛЫ

МӘГАРИФ
education
mağarif
просвещение

Оештыручысы:
«ТАТМЕДИА»
АКЦИОНЕРЛАР ҖӘМГЫЯТЕ

Февраль, 2016 ел 1913 елдан чыга № 2 (960)

## БУ САНДА:

**ТӨП ТЕМА – «ПЕДАГОГИК АТТЕСТАЦИЯ. ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕККӘ АНАЛИЗ ҺӘМ ҮЗАНАЛИЗ. ПЕДАГОГЛАРГА МЕТОДИК ЯРДӘМ КҮРСӘТҮНЕ ОЕШТЫРУ»**

### АНАЛИТИКА

ЕЛИЗАРОВ С. «Показать динамику менее чем за три года невозможно...» ... 3
САДЫКОВ М. Аттестация – путь к улучшению качества образования и повышению статуса учителя (Интервью с Ю.П.Прохоровым) ... 9
ХӘЙРУЛЛИН Р. Аттестация куркыныч түгел ... 12
ШАЯХМЕТОВА Р. Новые подходы к системе повышения квалификации: персонифицированная модель ... 14
О минимизации незаконных сборов и регламентации внеурочной деятельности ... 16
САБИРЗЯНОВ Т. «Была вера в то, что дети должны обучаться на родном языке...» (Интервью с Ф.Ф.Харисовым) ... 18

### МЕТОДИКА

САМЕРХАНОВ Т., ДЕЙНЕКИНА С. Создание системы непрерывного профессионального развития педагогических работников ... 21
ХАМИТОВА Г. Некоторые аспекты организации методической помощи педагогам ... 24
ҖАМАЛЕТДИНОВА З. Һәр гамәл анализ таләп итә ... 27
МИНДУБАЕВА Г. Яңача педагогик аттестация узу тәртибе ... 29
МӨСТӘКЫЙМОВА Р. Укытучыга тьютор ярдәме ... 31
ГАРИПОВА В., ГАЛИМОВА Г. Внеурочная деятельность по изучению иностранных языков ... 33
МУХАМЕТШИНА Т. Формирование целостной картины мира как одна из основных задач естественнонаучного образования ... 35

### ПРАКТИКА

БӘШӘРОВА М., ГАБДИНОВА З. Яхшылык итсәң – яшер, яхшылык күрсәң – белдер... ... 37
САЯХОВ И. Кабатланмас батырлык үрнәге ... 39
АНДРЕЕВА М. «Илең турында уйла...» ... 42
АЛМАЗОВА А. Милли сәнгатебезне дөньяга таныткан әсәр ... 44